**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**Коштаулы авыл җирлеге башкарма комитеты**

**КАРАРЫ**

2018 ел, 1 август N7

Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

“Гариза бирүче тарафыннан бердәм гариза бирү аркылы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә берничә дәүләт(муниципаль) хезмәтләре күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре күрсәтәүне оештыру турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Коштаулы у авыл җирлеге Башкарама комитеты **карар бирә**:

1 Коштаулы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 13маендыгы 5 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 нче пунктның “д” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“д) дәүләт(муниципаль) хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең, күпфункцияле үзәкнең функциясен үтәүгә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре күрсәтәүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 2010-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 11 өлеше нигезендә катнашучы оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (үтәмәүләренә) судка кадәр шикаять белдерү тәртибе.”

2.9 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2.9.Дәүләт(муниципаль) хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең, күпфункцияле үзәкнең функциясен үтәүгә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре күрсәтәүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 2010-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 11 өлеше нигезендә катнашучы оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (үтәмәүләренә) судка кадәр шикаять белдерү тәртибенә кагылышлы бүлектә күрсәтелә:”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы рәсми сайтының җирлек бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җирлек Башлыгы**